**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.11.2017 Балык Бистәсе штп. № 247пи

Пассажирлар ташуны оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләрен тормышка ашыру турында

Пассажирлар ташуны оештыру мәсьәләләрен тормышка ашыру өлкәсендә идарә итү функцияләрен башкару өлкәсендәге вәкаләтләрне камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 21 ноябрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында 2015 елның 13 июлендәге “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими пассажирлар һәм багажлар ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 220-ФЗ номерлы федераль законны һәм Татарстан Республикасының 2015 елның 26 декабрендәге “”Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими пассажирлар һәм багажлар ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында”гы федераль законны тормышка ашыру турында”гы 107-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру хакында” XXIII-3 номерлы карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территория үсеше бүлеге (алга таба – территория үсеше бүлеге) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты органы буларак (алга таба – Башкарма комитет) аның Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 21 ноябрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында 2015 елның 13 июлендәге “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажларны даими ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 220-ФЗ номерлы федераль законны һәм Татарстан Республикасының 2015 елның 26 декабрендәге “”Россия

Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажларны даими ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында”гы федераль законны тормышка ашыру турында”гы 107-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру хакында” XXIII-3 номерлы карарын тормышка ашыру буенча түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруын билгеләргә:

1.1)даими ташуларның муниципаль маршрутлары реестрын алып бару тәртибен, даими ташуларның муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү, бетерү тәртибен эшли һәм Башкарма комитет раславына кертә;

1.2) даими ташуларның муниципаль маршрутлары реестрын алып бара, Башкарма комитет тарафыннан даими ташуларның муниципаль маршрутларын билгеләүне, үзгәртү һәм бетерүне тәэмин итә;

1.3) ) даими ташуларның муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар ташуны гамәлгә ашыручы ташучыларның реестрын алып бара;

1.4)үзенең эш йөртергә хакы булган өлкә чикләрендә даими ташуларны планлаштыру документын әзерләү тәртибен эшли һәм Башкарма комитет раславына кертә, аның кабул ителүен һәм тормышка ашырылуын тәэмин итә;

1.5)Башкарма комитет тарафыннан ачык конкурста катнашуга гаризаларның критерийларын бәяләү өчен шкала билгеләүне тәэмин итә;

1.6)Башкарма комитет тарафыннан муниципаль килешү шартларын үтәү өчен контроль оештыру һәм гамәлгә ашыруны һәм Башкарма комитетның даими ташулар маршруты картасын бирүен тәэмин итә;

1.7) Башкарма комитет тарафыннан ташучыларга даими ташулар маршруты буенча ташуларны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими ташулар маршрутының картасын бирүне тәэмин итә;

1.8) гамәлдәге законнар нигезендә даими ташуларның муниципаль маршрутлары буенча гамәлгә ашырылучы пассажирлар ташуга тарифлар раслау турында тәкъдимнәр әзерли;

1.9)уңайсыз юл яки һава торышы-климат шартлары яисә гадәттән тыш хәлләр аркасында расланган расписаниеләр бозылганда маршрутлардагы ташучыларның пассажир транспорт чаралары эшен Башкарма комитет тарафыннан яраклаштыруны тәэмин итә;

1.10) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан даими ташуларның муниципаль маршрутлары буенча башлангыч һәм (яки) ахыргы тукталыш пункты сыйфатында файдаланырга рөхсәт ителүче тукталыш пунктларының исемлеген төзи һәм Башкарма комитет раславына кертә;

1.11)даими ташуларның муниципальара маршрутлары буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә тукталыш пунктларын билгеләү буенча тәкъдимнәр әзерли һәм Башкарма комитет тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына җибәрүне тәэмин итә;

1.12)зарурлык туганда даими ташуларның муниципаль маршрутлары буенча ташуларны көйләнмәгән тарифлар буенча гамәлгә ашыруга таләпләр эшли һәм Башкарма комитет тарафыннан раслауны тәэмин итә;

1.13)даими ташуларны оештыру һәм аларны гамәлгә ашыруга контроль булдыру мәсьәләләре буенча Башкарма комитетның башкарма хакимиятнең федераль органнары, Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары белән үзара бәйләнешен тәэмин итә;

1.14)транспорт комплексын идарә итү белән бәйле муниципаль программалар проектларын эшли һәм аларны Башкарма комитет каравына тәкъдим итә;

1.15) транспорт комплексын идарә итү белән бәйле программаларны финанс белән тәэмин итүне оештыру турында тәкъдимнәрне, бюджет заявкаларын формалаштыруны эшли;

1.16) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендәге гомуми файдаланудагы пассажир транспорты предприятиеләре эшчәнлеген анализлауны гамәлгә ашыра;

1.17)Башкарма комитет тарафыннан пассажирлар ташуга, автомобиль транспортында даими пассажирлар ташуны оештыру өлкәсендә ташучыларның кагыйдәләрне, стандартлар, нормативларны һәм шартнамәләрдәге кабул иткән йөкләмәләрен үтәвенә контрольне гамәлгә ашыруны оештыра һәм тәэмин итә;

1.18) киңәшмәләр, утырыш, штаб, комиссияләр өчен материаллар әзерли, халыкка транспорт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча район комиссияләре, төркемнәре эшендә катнаша;

1.19)Территория үсеше бүлеге компетенциясе белән бәйле бәхәсләр буенча Башкарма комитет исеменнән судларда катнаша;

1.20) үзенең компетенциясе чикләрендә даими ташулар оештыруны җайга салучы муниципаль норматив-хокукый актлар әзерли;

1.21) муниципаль норматив-хокукый актлар белән территория үсеше бүлеге компетенциясенә кертелгән пассажирлар ташуны оештыру мәсьәләләрен тормышка ашыру кысаларында башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2.”Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль заказ хезмәте” муниципаль казна учреждениесенең (алга таба – “Муниципаль заказ хезмәте” МКУ се) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 21 ноябрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында 2015 елның 13 июлендәге “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажларны даими ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 220-ФЗ номерлы федераль законны һәм Татарстан Республикасының 2015 елның 26 декабрендәге “”Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажларны даими ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында”гы федераль законны

тормышка ашыру турында”гы 107-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру хакында” XXIII-3 номерлы карарын тормышка ашыру буенча Башкарма комитетның түбәндәге вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын билгеләргә:

2.1)Башкарма комитетның килешүле идарәчесе белән берлектә үзенең муниципаль хокукый актлар белән расланган компетенциясе чикләрендә Башкарма комитет тарафыннан гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирларны һәм багажны даими ташуларның муниципаль маршрутлары буенча даими ташуларның муниципаль заказ бирүчесе функцияләрен үтәүне тәэмин итә;

2.2) үзенең муниципаль хокукый актлар белән расланган компетенциясе чикләрендә Башкарма комитет тарафыннан, 2015 елның 13 июлендәге “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажларны даими ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 220-ФЗ номерлы федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эш, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән килешүле система тәртибендә, көйләнгән тарифлар буенча даими ташуларны гамәлгә ашыру белән бәйле эшләрне башкаруга муниципаль килешүләргә бәяләмә бирүне тәэмин итә;

2.3) ) үзенең муниципаль хокукый актлар белән расланган компетенциясе чикләрендә даими ташуларның муниципаль маршрутлары буенча көйләнмәгән тарифлар буенча ташуларны гамәлгә ашыру хокукына Башкарма комитетның ачык конкурс оештыручы функцияләрен үтәвен тәэмин итә (алга таба – ачык конкурс);

2.4) муниципаль хокукый актлар белән “Муниципаль заказ хезмәте” МКУ се компетенциясенә кертелгән пассажирлар ташуны оештыру мәсьәләләрен тормышка ашыру кысаларында бүтән вәкаләтләрне дә гамәлгә ашыра.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 5 апрелендәге “Маршрутлы пассажир ташуларны оештыру турында” 77пи номерлы карарының көчен югалтуын танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

5.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче Р.Х. Хабибуллин